ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 24 » апрель 2023 ел** **№ 12**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» Утар-Атыавыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 08 сентябрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 21.12.2021 елгы 414-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында кодексын, Арча муниципаль районы Утар-Атыавыл җирлеге уставын гамәлгә ашыру, Төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү өлкәсендә контрольне көчәйтү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 08 сентябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Атыавыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.7.1 пунктның 7 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яки Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ УТАР АТЫНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ ОГРН 1121609000198
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УТАР АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609012653